ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 декабрь, 2018 ел № 28/5

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар планы чорына бюджеты турында

Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, Россия Федерациясенең Салым кодексы, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/6 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамә нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан тәкъдим ителгән 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проектын һәм 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләрен караганнан соң,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Расларга:

1) 2019 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының (алга таба – шәһәр бюджеты) төп характеристикаларын:

– шәһәр бюджетының фаразланучы керемнәренең гомуми күләмен 8 689 088,59 мең сум итеп;

– шәһәр бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 8 689 088,59 мең сум итеп;

2) 2020 елга һәм 2021 елга шәһәр бюджетының төп характеристикаларын:

– шәһәр бюджетының фаразланучы керемнәренең гомуми күләмен 2020 елга 8 747 168, 49 мең сум һәм 2021 елга 8 818 542,09 мең сум итеп;

3) шәһәр бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2020 елга 8 747 168, 49 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган

чыгымнар күләмен 134 429,11 мең сум, һәм 2021 елга 8 818 542,09 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар күләмен 271 694,47 мең сум итеп.

2. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар планы чорына шәһәр бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 1 нче кушымтада каралган тәртиптә билгеләргә.

3. 2020 елның 01 гыйнварына эчке муниципаль бурычның югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләрнең югары чиген 0,00 мең сум күләмендә билгеләргә.

4. 2021 елның 01 гыйнварына эчке муниципаль бурычның югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләрнең югары чиген 0,00 мең сум күләмендә билгеләргә.

5. Билгеләргә:

1) 2022 елның 01 гыйварына эчке муниципаль бурычның югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләрнең югары чиген 0,00 мең сум күләмендә;

2) муниципаль бурычның иң чик күләмен:

2019 елда – 0,00 мең сум күләмендә;

2020 елда – 0,00 мең сум күләмендә;

2021 елда – 0,00 мең сум күләмендә.

6. Шәһәр бюджетында 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар планы чорына фаразланучы бюджет керемнәре күләмен 2 нче кушымтада каралганча исәпкә алырга.

7. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар планы чорына шәһәр бюджетына керемнәрне чигерү нормативларын 3 нче кушымтада каралган тәртиптә расларга.

8. Расларга:

1) 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар планы чорына шәһәр бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген 4 нче кушымтада каралганча;

2) 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар планы чорына шәһәр бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген 5 нче кушымтада каралганча.

9. Бюджет чыгымнары классификациясенең бүлек һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгым төрләре буенча бюджет ассигнованиеләре бүленешен расларга:

1) 2019 елга 6 нчы кушымтада каралган тәртиптә;

2) 2020 һәм 2021 елларга 7 нче кушымтада каралган тәртиптә.

10. Шәһәр бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

1) 2019 елга 8 нче кушымтада каралганча;

2) 2020 һәм 2021 елларга 9 нчы кушымтада каралганча.

11. Шәһәр бюджетының ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2019 елга

1 380,00 мең сум, 2020 елга 1 380,00 мең сум, 2021 елга 1 380,00 мең сум итеп расларга.

12. Шәһәр бюджетында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен һәм аны алыштыручы физик затлар кеременә салымнарны чигерүнең өстәмә нормативларын исәпкә алырга:

1) 2019 елга 943 981,20 мең сум күләмендә, шул исәптән физик затлар керемен салымнарны чигерүнең өстәмә нормативларын алыштыру өчен – 9,7 процент, акчага күчереп хисаплаганда – 43 857,80 мең сум;

2) 2020 елга 1 023 347,50 мең сум күләмендә, шул исәптән физик затлар керемен салымнарны чигерүнең өстәмә нормативларын алыштыру өчен – 10,1 процент, акчага күчереп хисаплаганда – 35 916,60 мең сум;

3) 2021 елга 1 300 453,70 мең сум күләмендә, шул исәптән физик затлар керемен салымнарны чигерүнең өстәмә нормативларын алыштыру өчен – 12,3 процент, акчага күчереп хисаплаганда – 26 757,90 мең сум.

14. Шәһәр бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан күчерелүче субвенцияләрне исәпкә алырга:

1) 2019 елда 3 311 924,29 мең сум күләмендә, шул исәптән:

– муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен субвенцияләрне 2 116 701,30 мең сум күләмендә;

– муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен субвенцияләрне 1 138 484,50 мең сум күләмендә;

– мәгариф өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 10 260,30 мең сум, шул исәптән методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итүгә 9 860,40 мең сум һәм идарә чыгымнарын гамәлгә ашыруга 399,90 мең сум күләмендә;

– балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 3 386,90 мең сум күләмендә;

– административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 846,10 мең сум күләмендә;

– дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 399,90 мең сум күләмендә;

– халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 710,50 мең сум күләмендә;

– архив эше өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 229,40 мең сум күләмендә;

– опека һәм попечительлек өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 7 005,70 мең сум күләмендә;

– күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 3 483,40 мең сум күләмендә;

– административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 0,59 мең сум күләмендә;

– хайваннар арасындагы авыруларны кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кешеләргә һәм хайваннарга хас авырулардан саклау буенча чаралар үткәрүне оештыру өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 1 057,70 мең сум күләмендә, шул исәптән түләмә авырулы терлекләр каберлеген һәм биотермик чокырларны карауга 35,50 мең сум күләмендә һәм күзәтүчесез хайваннарны тотуга, карауга һәм исәбен җайга салуга 1 022,20 мең сум күләмендә;

– йогышлы авырулар тудыручы чыганакларда, шулай ук йогышлы авырулар барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм биналарда лаборатор тикшерү методларын кулланып үткәрелә торган дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация, санитария-эпидемия (профилактика) чаралары үткәрүне гамәлгә ашыруны оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 8 167,90 мең сум күләмендә;

– Россия Федерациясендә гомуми юрисдикция федераль судларының присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү өчен субвенцияләрне 134,70 мең сум күләмендә;

– җәмәгать урыннарында алкоголь кулланган хәлдә булган һәм мөстәкыйль хәрәкәтләнү яки тирә-як мохиттә ориентлаша алу сәләтен югалткан затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 4 487,90 мең сум күләмендә;

– гражданнар хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне 15 462,20 мең сум күләмендә;

2) 2020 елга 3 313 279,09 мең сум күләмендә һәм 2021 елга 3 314 662,59 мең сум күләмендә, шул исәптән:

– муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен субвенцияләрне:

2020 елга –2 116 701,30 мең сум күләмендә;

2021 елга –2 116 701,30 мең сум күләмендә;

– муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен субвенцияләрне:

2020 елга 1 138 484,50 мең сум күләмендә;

2021 елга 1 138 484,50 мең сум күләмендә;

– мәгариф өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 10 618,10 мең сум, шул исәптән методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итүгә 10 218,20 мең сум һәм идарә чыгымнарын гамәлгә ашыруга 399,90 мең сум күләмендә;

2021 елга 10 608,50 мең сум, шул исәптән методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итүгә 10 608,50 мең сум һәм идарә чыгымнарын гамәлгә ашыруга 399,90 мең сум күләмендә;

– балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 4 498,20 мең сум күләмендә;

2021 елга 4 504,30 мең сум күләмендә;

– административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 846,10 мең сум күләмендә;

2021 елга 846,10 мең сум күләмендә;

– дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 399,90 мең сум күләмендә;

2021 елга 399,90 мең сум күләмендә;

– халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 710,50 мең сум күләмендә;

2021 елга 710,50 мең сум күләмендә;

– архив эше өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 229,40 мең сум күләмендә;

2021 елга 229,40 мең сум күләмендә;

– опека һәм попечительлек өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 7 005,70 мең сум күләмендә;

2021 елга 7 005,70 мең сум күләмендә;

– күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 3 483,40 мең сум күләмендә;

2021 елга 3 483,40 мең сум күләмендә;

– административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 0,59 мең сум күләмендә;

2021 елга 0,59 мең сум күләмендә;

– хайваннар арасындагы авыруларны кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кешеләргә һәм хайваннарга хас авырулардан саклау буенча чаралар үткәрүне оештыру өлкәсендәге дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 1 057,70 мең сум күләмендә, шул исәптән түләмә авырулы терлекләр каберлеген һәм биотермик чокырларны карауга 35,50 мең сум күләмендә һәм күзәтүчесез хайваннарны тотуга, карауга һәм исәбен җайга салуга 1 022,20 мең сум күләмендә;

2021 елга 1 057,70 мең сум күләмендә, шул исәптән түләмә авырулы терлекләр каберлеген һәм биотермик чокырларны карауга 35,50 мең сум күләмендә һәм күзәтүчесез хайваннарны тотуга, карауга һәм исәбен җайга салуга 1 022,20 мең сум күләмендә;

- йогышлы авырулар тудыручы чыганакларда, шулай ук йогышлы авырулар барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм биналарда лаборатор тикшерү методларын кулланып үткәрелә торган дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация, санитария-эпидемия (профилактика) чаралары үткәрүне гамәлгә ашыруны оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 8 494,60 мең сум күләмендә;

2021 елга 8 847,90 мең сум күләмендә;

– Россия Федерациясендә гомуми юрисдикция федераль судларының присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү өчен субвенцияләрне:

2020 елга 141,40 мең сум күләмендә;

2021 елга 141,40 мең сум күләмендә;

– җәмәгать урыннарында алкоголь кулланган хәлдә булган һәм мөстәкыйль хәрәкәтләнү яки тирә-як мохиттә ориентлашу сәләтен югалткан затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 4 612,60 мең сум күләмендә;

2021 елга 4 731,30 мең сум күләмендә.

– гражданнар хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләрне:

2020 елга 15 995,10 мең сум күләмендә;

2021 елга 16 502,50 мең сум күләмендә;

14. Муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен расларга:

1) 2019 елга 40 700,00 мең сум күләмендә;

2) 2020 елга 42 800,00 мең сум күләмендә;

3) 2021 елга 44 100,00 мең сум күләмендә.

15. Муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне

оештыруга, муниципаль белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыруга, муниципаль белем бирү оешмаларында балаларны тотуны, карауны һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруга, шулай ук каникул вакытында балаларның ялын оештыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләрне расларга:

1) 2019 елга 455 910,70 мең сум күләмендә;

2) 2020 елга 356 740,80 мең сум күләмендә;

3) 2021 елга 219 993,40 мең сум күләмендә.

16. Шәһәр бюджетында Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизель һәм (яки) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына акцизлардан җирле бюджетларга Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 маддәсе нигезендә күчерелергә тиешле түләүләрнең дифференциацияләнгән нормативы күләмен 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар планы чорына 4,1524 1751процент күләмендә исәпкә алырга.

17. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 маддәсе нигезендә шәһәр бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләрнең күләме:

1) 2029 елга 2 277,90 мең сум;

2) 2020 елга 4 341,60 мең сум;

3) 2021 елга 19 995,80 мең сум.

18. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарын 2019 елда, 2020 һәм 2021 еллар планы чорында муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең яңа челтәреннән тыш, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз дип билгеләргә.

19. Әлеге Карарда юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товар (эшләр, хезмәтләр) җитештерүчеләргә каралган субсидияләр Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә.

20. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары шәһәр бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне төзелгән килешүләр нигезендә башкаралар.

21.Билгеләргә:

1) 2019 елда, 2020 һәм 2021 еллар планы чорында шәһәр бюджетына муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль казна предприятиеләре табышының салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләрне керткәннән соң кала торган өлешен күчерү 2018 елда, 2019 һәм 2020 елларда алынган саф табышның 50 проценты күләмендә

– 2018 ел нәтиҗәләре буенча – 2019 елның 01 сентябренә кадәр;

– 2019 ел нәтиҗәләре буенча – 2020 елның 01 сентябренә кадәр;

– 2020 ел нәтиҗәләре буенча – 2021 елның 01 сентябренә кадәр гамәлгә ашырыла дип билгеләргә

22. Акцияләре Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкендә булган акционерлык җәмгыятьләренең идарә органнарында Яр Чаллы

шәһәре муниципаль берәмлеге вәкилләренә, акционерлык җәмгыятьләренең идарә органнары (директорлар советы, күзәтү советы, акционерларның гомуми җыелышы) тарафыннан 2018 ел нәтиҗәләре буенча чиста табышны һәм дивидентлар түләүне бүлү мәсьәләләре буенча карарлар кабул иткәндә, 2019 елның 01 сентябренә кадәр срокта (әгәр җәмгыять уставы тарафыннан башка срок билгеләнмәсә) акцияләр буенча дивидентларны еллык нәтиҗәләр буенча чиста табышның 50 проценты күләмендә акчалата түләү өчен тавыш бирергә дип билгеләргә.

23. Яр Чаллы шәһәре муниципаль хезмәткәрләренә торак төзү яки сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү, шулай ук санаторий-курортларда дәвалану өчен юллама бәясен түләү буенча өстәмә гарантияләр хакында муниципаль хокукый актның гамәли вакытын 2020 елның 01 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

24. Әлеге Карар 2018 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

25. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев